ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

## ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район,
село Старые Киязлы, ул. Центральная д.57
Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 106166500 2332,
ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001

## Карар

8 ноябрь, 2024 нче ел № 10

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
бюджеты керемнәренең
Баш администраторлары
исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160 статьясындагы 3.2 пунктының өченче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең кушымтада бирелә торган Баш администраторлары исемлеген расларга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлегенен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләргә карата кулланыла.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитетының 25.10.2023 елның 11 номерлы карарын 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында.

Башкарма комитет җитәкчесе

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Дэулэтшин

Расланган
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитеты карары белән
08.11.2024 ел, № 10

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары Исемлеге

| Бюджет классификациясе коды | | |
|---|---|---|
| Керемнәр нең баш администраторы | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең бюджет керeменең төре | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең бюджет керeменең баш администраторлары исеме / Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең бюджет керeменең төре |
| 1 | 2 | 3 |
| 170 | Аксубай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | |
| 170 | 111 05025 10 0000 120 | Аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук авыл җирлекләре (муниципаль бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш)милкендәге җирләр өчен аренда килешүләре төзү хокукын сатудан алынган акчалар |
| 170 | 111 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре һәм алар тарафыннан төзелгән учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш)арендага бирүдән керемнәр |
| 170 | 111 05075 10 0000 120 | Авыл җирлекләре казнасын тәшкил иткән мөлкәтне арендага бирүдән керемнәр (җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 170 | 111 09045 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге мөлкәттән (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш)файдаланудан башка керемнәр |
| 170 | 114 02052 10 0000 410 | Авыл җирлекләре идарәсе органнары (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан күрсәтелгән мөлкәт буенча төп акчаларны гамәлгә ашыру өлешендәге керемнәр |
| 170 | 114 02052 10 0000 440 | Авыл җирлекләре идарәсе органнары (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендәге керемнәр |
| 170 | 114 02053 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге башка мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар |

| | | |
|---|---|---|
| | | предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан керемнәр күрсәтелгән мөлкәт буенча төп акчаларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 170 | 114 02053 10 0000 440 | Күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә авыл җирлекләре милкендәге башка мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан керемнәр |
| 170 | 114 06025 10 0000 430 | Авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләрен сатудан кергән табыш (муниципаль бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 170 | 117 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы | | |
| 300 | 1 08 04020 01 1000 110 | Нотариаль гамәлләр кылуга Россия Федерациясе закон актлары нигезендә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (түләү суммасы (яңадан исәпләү, недоимка һәм тиешле түләү буенча, шул исәптән юкка чыгарылган түләү буенча бурыч)) |
| 300 | 1 08 07175 01 1000 110 | Муниципаль район җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөк ташуны гамәлгә ашыручы автомобиль юллары буенча җирлекләр бюджетларына күчерелә торган транспорт чараларына махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы (түләү суммасы (яңадан исәпләү, недоимка һәм тиешле түләү буенча, шул исәптән юкка чыгарылган түләү буенча бурыч)) |
| 300 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән башка керемнәр |
| 300 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә кергән керемнәр |
| 300 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 300 | 1 16 01074 01 0000 140 | Муниципаль контроль органнары вазыйфаи затлары ачыклаган милекне саклау өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлеге тарафыннан билгеләнгән административ штрафлар |
| 300 | 1 16 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 300 | 1 16 07010 10 0000 140 | Сатучы (подрядчы, башкаручы) тарафыннан авыл җирлегенең казна учреждениесе, Муниципаль орган төзегән муниципаль контрактта каралган йөкләмәләрне үтәү срогы чыккан очракта түләнгән штрафлар, неустойкалар, пенялар |
| 300 | 1 16 07090 10 0000 140 | Муниципаль орган, муниципаль казна учреждениесе каршында йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән бүтән |

| | | |
|---|---|---|
| | | штрафлар, неустойкалар, пенялар |
| 300 | 1 16 10031 10 0000 140 | Авыл җирлегe бюджеты акчаларын алучылар файда алучы иминият очраклары килеп чыкканда зыянны каплау |
| 300 | 1 16 10081 10 0000 140 | Башкаручының (муниципаль юл фонды акчалары хисабына финанслана торган муниципаль контракттан тыш) берьяклы баш тартуы сәбәпле, авыл җирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән төзелгән муниципаль контрактны өзгәндә китерелгән зыянны каплау максатларында түләүләр |
| 300 | 1 16 10123 01 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән, муниципаль берәмлек бюджетына 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча( муниципаль юл фондын формалаштыруга юнәлдерелгән керемнәрдән тыш) күчерелергә тиешле бурычларны түләү счетына кергән акча түләтүдән (штрафлардан) кергән керемнәр |
| 300 | 1 16 10061 10 0000 140 | Муниципаль орган (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт төзүдән баш тартып килгән зыяннарны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш) авыл җирлеге бюджетына күчерелергә тиешле башка акчаларны каплау максатларында түләүләр. |
| 300 | 1 16 10100 10 0000 140 | Бюджет акчаларын законсыз яки максатсыз куллану нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата штрафлар.( авыл җирлеге бюджеты өлешендә) |
| 300 | 1 16 11050 01 0000 140 | Әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны (аеруча саклаулы табигать территорияләрендә әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләр), муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш |
| 300 | 1 16 11064 01 0000 140 | Авыр авырлыктагы һәм (яки) зур габаритлы йөк ташучы транспорт чаралары тарафыннан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау максатларында түләнә торган түләүләр |
| 300 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 300 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының башка салым булмаган керемнәре |
| 300 | 117 14030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым чаралары |
| 300 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 300 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына җирле бюджетлардан башка субсидияләр |
| 300 | 2 02 35118 10 0000 150 | Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл |

| | | |
|---|---|---|
| | | җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 300 | 2 02 40014 10 0000 150 | Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 300 | 2 02 45160 10 0000 150 | Хакимият органнары тарафыннан башка дәрәҗәдәге карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 300 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |
| 300 | 2 04 05010 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл җирлекләре бюджеты акчаларын алучылар өчен грантлар бирү |
| 300 | 2 04 05020 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл җирлекләре бюджеты акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 300 | 2 04 05099 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалардан авыл җирлекләре бюджетларына башка түләүсез керемнәр |
| 300 | 2 08 05000 10 0000 150 | Салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне кире кайтару (зачет) өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына), шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләнгән суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару өчен күчерелә |
| 300 | 2 08 10000 10 0000 150 | Түләтүне гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) күчерүләр |
| 300 | 2 18 60010 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларының узган еллар муниципаль районнар бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар калдыкларын кире кайтарудан кергән керемнәре |
| 300 | 219 45160 10 0000 150 | Хакимият органнары тарафыннан башка дәрәҗәдәге карарлар нәтиҗәсендә авыл җирлекләре бюджетларыннан барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтару |
| 300 | 219 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнештәге башка субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |